**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә кертелгән карантинны бетерергә:
Апас районының Танай-Турай авылы;
Зеленодольск районының Ореховка авылы;
Тукай районының Таулык авылы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2018 елның 10 сентябрендәге ПУ-637 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 14 ноябрь
№ ПУ-776